Казан шәһәре Думасының
2024 елның 7 августындагы 7-31 номерлы карары

**Казан шәһәре Думасының**
**2009 елның 12 мартындагы 11-39 номерлы**
**«Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының**
**муниципаль вазифаларын даими нигездә биләүче затларга**
**хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары турында»гы карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының муниципаль вазифаларын даими нигездә биләүче затларның социаль гарантияләрен тәэмин итү максатыннан Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. Казан шәһәре Думасының 2009 елның 12 мартындагы 11-39 номерлы «Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының муниципаль вазифаларын даими нигездә биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары турында»гы карарының (Казан шәһәре Думасының 2010 елның 27 октябрендәге 19-1 номерлы, 2012 елның 7 июнендәге 21-14 номерлы, 2012 елның 24 октябрендәге 9-17 номерлы, 2013 елның 14 мартындагы 14-21 номерлы, 2013 елның 16 октябрендәге 16-25 номерлы, 2014 елның 28 августындагы 5-35 номерлы, 2014 елның 3 октябрендәге 29-36 номерлы, 2017 елның 17 августындагы 11-19 номерлы, 2018 елның 17 апрелендәге 13-25 номерлы, 2019 елның 20 июнендәге 15-34 номерлы, 2020 елның 21 сентябрендәге 20-1 номерлы, 2022 елның 13 октябрендәге 3-17 номерлы, 2022 елның 19 декабрендәге 22-19 номерлы, 2024 елның 26 июнендәге 5-30 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 5 номерлы кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Муниципаль вазифаларны даими нигездә биләүче затларга премия бирү Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә вәкаләтләрне уңышлы башкарган, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне гамәлгә ашырган, Казан шәһәре җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең гомуми нәтиҗәсенә шәхси өлеш керткән өчен эш нәтиҗәләреннән чыгып (алга таба – эш нәтиҗәләре буенча премия) гамәлгә ашырыла.

Эш нәтиҗәләре буенча премия билгеле бер эш нәтиҗәләре өчен һәм билгеле бер эш чоры (ай, квартал, ел) өчен бер мәртәбә түләнергә мөмкин»;

1.2. 3 пунктны «яки абсолют күләмдә (сумнарда)» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның йогынтысы 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**